КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 19 март г.Казань № 159

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 март, 129 нчы; 2021 ел, 24 май, 365 нче; 2021 ел, 15 ноябрь, 1076 нчы; 2022 ел, 5 декабрь, 1286 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы; 2023 ел, 31 июль, 913 нче; 2023 ел, 16 октябрь, 1313 нче; 2024 ел, 30 май, 376 нчы; 2024 ел, 16 декабрь, 1147 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары Татарстан Республикасында даими яшәүче түбәндәге яңа туган балалы гаиләләр тәэмин ителә дип билгеләргә:

җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 ел, 20 октябрь, 1122 нче карарының 1 пунктындагы беренче абзацында һәм $1^1$ пунктында күрсәтелгән Россия Федерациясе гражданнары.»;

әлеге карар белән расланган Яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче түбәндәге яңа туган балалы гаиләләр алырга хокуклы:

балалар кирәк-яракларының бүләк комплектын алу хокукын билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме күләме турында белешмә кәгазе бирелгән датага җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 ел, 20 октябрь, 1122 нче карарының 1 пунктындагы беренче абзацында һәм $1^1$ пунктында күрсәтелгән Россия Федерациясе гражданнары.

Балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап балалар туганда бирелә.

Балалар кирәк-яракларының бүләк комплекты составы Нигезләмәнең кушымтасында китерелә.»;

2.5 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бала тудырган хатын-кыз тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 ел, 20 октябрь, 1122 нче карарының 1 пунктындагы беренче абзацында һәм $1^1$ пунктында күрсәтелгән гражданнар категориясенә баланың атасы каравын раслый торган документ тапшырылган очракта, балалар кирәк-яракларының бүләк комплектын бирү гаиләнең җан башына уртача керемен исәпкә алмыйча гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин